

Казанда туган тел һәм татар әдәбияты укытучыларының «Туган тел» мастер-классының Ботенроссия конкурсы финал этабы 2021 елның 22-24 мартында узды.
Конкурснын финалына Татарстан Республикасыннан 17 татар теле, 10 - рус теле, 6 - чуваш теле, 4 - мари һәм 2 - мордва теле (барлыгы 50) укытучысы катнаштылар. Моннан тыш, 10 татар теле һәм әдәбияты укытучысы РФнен башка субъектларыннан- Башкортостаннан, Самарадан, Пензадан, Кировтан, Мордовиядән, Ульяновсктан, Чувашиядан, Томәннән, Перьмнан, Свердловсктан. Бу ярышта Мордовия татарларын Ләмберә районы Черемиш топ мәктәбенен югары квалификацияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы Фазия Фәрит кызы Боярова тәгъдим итте. Ул шундый конкурсларда дүртенче тапкыр катнаша; һәрвакыт нәрсәдер яулап кайта. Бу ярышта да шулай булды. Ярышнын беренче конендә, 22 мартта чарада катнашучылар үзләренен мастер-классларын үткәргәннәр. Фазия Фәрит кы- зы үткәргән мастер-классынын темасы - «Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә уен технологияләре», ә ботен Россия укытучылары «Текст тоз һәм аны дорес укы», «Лексик футбол», «Золушка», «Немой диктант» үткәргәннәр. Ф.Ф.Боярова үзе дә башка тобәкләр укытучыларынын мастер-классларында актив катнашкан.
23 март конне үткән чаралар бай эчтә- лекле булганнар: конкурсантлар иртәдән проектлар яклаганнар. Бу конкурста күп кызыклы темалар тәкъдим ителгән. Биредә Фазия Фәрит кызы «Балалар мәдәнияте аша мәдәниятләр диалогы» проектын унышлы яклаган. Аннары «Укучыларнын татар телен һәм әдәбиятын ойрәнүгә мотивация» темасына оештырылган түгәрәк остәлдә катнашкан безнен конкурсантыбыз.
- Бик кызык булды, мин үзем очен күп нәрсә алдым һәм киләсе дәресләрдә кулланырмын дип ометләнәм, - дип фикер алышты ул. - Әмма ин дулкынландыргыч, әлбәттә, чаранын ябылу тантанасы иде. Татар теле һәм әдәбияты укытучыларынын Ботенроссия мастер-классындагы «Про-фессиясенә тугрылыклы» номинациясе лауреаты дипломын алуыма мин бик шат. Үз бүләкләрен безгә шулай ук Ботендонья татар конгрессы, «Энже» зәркән салоны да тапшырдылар. Әмма катнашучыларга ин кадерле бүләкләр дип мин Милли китапханәгә һәм, әлбәттә, театрга экскурсияләрне саныйм, - ди конкурс дипломанты Фазия Фәрит кызы Боярова.

Наилә НАСЫРОВА